**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№8482**
**27.12.2021**

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2021 елның 19 августындагы 5526 номерлы карарының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә Янгынга каршы куркынычсызлык режимы кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чараларын пиротехник эшләнмәләр кулланып оештыру һәм үткәрү тәртибе турында» 2021 елның 19 августындагы 5526 номерлы карарына, 2 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                     Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 27 декабрендәге
8482 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2021 елның 19 августындагы
5526 номерлы карарына
2 нче кушымта

Халыкның Яр Чаллы шәһәре территориясендә махсуслаштырылган кибетләрдә яки кибетләрнең махсуслаштырылган бүлекләрендә ирекле сату рөхсәт ителә торган I-III класс куркынычлы (куркыныч зона радиусы 0,5 тән 20 метрга кадәр) көнкүреш пиротехник эшләнмәләрдән файдалану өчен билгеләнгән урыннар исемлеге

1. «Җиңү» паркы» – чыршы янәшәсендәге әйләндереп алынган спорт мәйданчыгы («Шахмат-шашка клубы» административ бинасыннан 300 м көнбатышта, 20/07 торак йортыннан 750 м көньякта).

2. Шәһәр пляжы янындагы мәйданчык (Раскольников урамы буенча 60 йорт, 3 катлы Таунхаустан 350 м көньяк-көнбатышта), 38/05 торак йорттан 400 м көнбатышта).

3. «Төзүче» БЯСМ» МАӨББУ стадионы артындагы мәйданчык (Мәләкәс елгасы яр буенда «Төзүче» БЯСМ» МАӨББУ стадионыннан 300 м көнчыгышта, «Яр Чаллы сәнгать колледжы» ДАҺББУдан 350 м көньяк-көнчыгышта).

4. Ипподром территориясендәге мәйданчык (3 катлы 61/32 торак йортның Д блогыннан 300 м көньяк-көнчыгышта, Чулман проспекты буенча күпкатлы 94 торак йорттан (46/03) 350 м төньякта).

5. Раскольников урамындагы 34/01 торак йорт һәм «Прикамский» ГСК арасындагы мәйданчык («Прикамский» ГСКдан 500 м көнбатышта, 34/01 торак йорттан 440 м көньяк-көнчыгышта).

6. Габдулла Тукай яр буенда Шәһәр пляжы янындагы мәйданчык (Яр Чаллы Мөхтәсибәте Тәүбә мәчетеннән 480 м төньяк-көнбатышта, Габдулла Тукай яр буе, 10/70 торак йорттан  (93/100) 307 м көнчыгышта).

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева